КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 сентябрь г.Казань № 775

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбрәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 сентябрь, 696 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбрәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 сентябрь, 696 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар» сүзләрен «бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләренә

алмаштырырга, «Татарстан Республикасы белән идарә итә һәм эш итә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар» сүзләрен «бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеге» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы белән идарә итә һәм эш итә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырганда Тәртипкә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбрәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 сентябрь, 696 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 сентябрь, 775 нче
карары редакциясендә)

Җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбрәк баласы булган гражданнарга бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеге тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 5, $19^1$ пунктларын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде һәм шәһәр округлары территориясендә даими яшәүче өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга (алга таба – күпбалалы гаилә) милек хокукы чикләнмәгән, идарә һәм эш итү вәкаләтләре Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган яки шәһәр округы милкенә тапшырылган җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлеге) бирү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы (алга таба – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары (алга таба – муниципаль районның җирле үзидарә органы) һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба шул ук эзлеклелектә – шәһәр округлары, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары) үзара хезмәттәшлеге механизмын билгели.

## II. Милек хокукы чикләнмәгән, идарә һәм эш итү вәкаләтләре Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләрен бирү максатларында үзара хезмәттәшлек тәртибе

2.1. Үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максаты белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы шәһәр округының җирле үзидарә органы белән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү төзи.

2.2. Үзара хезмәттәшлек Татарстан Республикасы тарафыннан идарә һәм эш итела торган җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен күпбалалы гаиләләргә бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмашудан һәм чаралар уздыруны оештырудан гыйбарәт. Үзара хезмәттәшлек даими нигездә башкарыла.

2.3. Шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан үзара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы тарафыннан идарә һәм эш ителә торган җир кишәрлекләреннән файдалану максатын саклап, җир кишәрлекләрен барлыкка китерү;

күпбалалы гаиләләргә бирү максатларында җир кишәрлекләре исемлеген төзү;

һәр мөрәҗәгать итүчегә уникаль исәпкә алу номеры биреп, җир кишәрлеген алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү һәм алып бару;

җир кишәрлеген алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә кертү йә кертүдән баш тарту турында карар кабул итү;

законнар нигезендә җир кишәрлеген сайлап алу актын рәсмиләштереп, җир кишәрлеген сайлап алу процедурасын үткәрү;

тәкъдим ителә торган җир кишәрлекләре карталарында сайланган җир кишәрлекләре тамгасы һәм тиешле мәгълүматны шәһәр округының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында алга таба урнаштыру;

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 9 пункты нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән күпбалалы гаиләләр буенча документлар архивын алып бару;

җир кишәрлекләре бирүгә гаризалар реестрын, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән нигезләр буенча җир кишәрлекләре милеккә бирелгән (тапшырылган) гражданнар реестрын алып баруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының күпбалалы гаиләгә җир кишәрлеге бирү турында карары проектын (алга таба – җир кишәрлеге бирү турында карар) һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты проектын әзерләү;

бирелгән җир кишәрлекләренә хокуклар көчүне рәсмиләштерүне тәэмин итү;

күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүне мониторинглау.

2.4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы үзара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына консультация, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясындагы 10 пунктында каралган документларны карау, җир кишәрлеген бирү турында карар кабул итү һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актына кул кую.

2.5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы шәһәр округының җирле үзидарә органыннан күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүгә бәйле документларны соратып алырга хокуклы.

## III. Милек хокукы чикләнмәгән, идарә һәм эш итү вәкаләтләре Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү

3.1. Җир кишәрлеген бирү турында карар формасы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан раслана.

3.2. Шәһәр округының җирле үзидарә органы күпбалалы гаилә һәм шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан җир кишәрлеген сайлап алу актына кул куйган көннән алып дүрт эш көне эчендә җир кишәрлеген бирү турында карар проектын, күпбалалы гаилә тарафыннан имзаланган җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын әзерләүне һәм, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан җир кишәрлеге бирү турында карар кабул итү максатларында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясындагы 10 пунктында каралган документларның күчермәләрен теркәп, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгына җибәрүне гамәлгә ашыра.

3.3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә түбәндәге гамәлләрнең берсен башкара:

җир кишәрлеген бирү турында карар кабул итә, җир кишәрлеген бирү турындагы карарны, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын һәм әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларны шәһәр округының җирле үзидарә органына җибәрә;

әгәр шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган документларда тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүмат булса, шәһәр округының җирле үзидарә органы күрсәткән искәрмәләрне бетерү максатларында документларны кире кайтара.

3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, шәһәр округының җирле үзидарә органы документлар кергән көннән алып биш эш көне эчендә ачыкланган искәрмәләрне бетерә һәм документларны Татарстан Республикасы Җир һәм азык-төлек министрлыгына кабат карауга җибәрә.

3.5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан документларны кабат карау әлеге Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Шәһәр округы милкенә тапшырылган җир кишәрлекләрен бирү максатларында үзара эшчәнлек тәртибе

4.1. Үзара хезмәттәшлек Татарстан Республикасы Җир кодексының 20 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракларда шәһәр округы милкенә тапшырылган җир кишәрлекләрен күпбалалы гаиләләргә бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмашудан һәм чаралар уздыруны оештырудан гыйбарәт. Үзара хезмәттәшлек даими нигездә башкарыла.

4.2. Муниципаль районның җирле үзидарә органы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән хезмәттәшлек итеп, күпбалалы гаиләләргә бирү максатларында муниципаль район территориясендә җир кишәрлекләре исемлеген билгеләү;

әлеге Тәртипнең I бүлегендә күрсәтелгән җир кишәрлекләрен шәһәр округы милкенә тапшыру чаралары;

территориаль планлаштыру документларына, шәһәр төзелешен зоналаштыру документларына һәм муниципаль район территориясен планлаштыру

документларына үзгәрешләр кертергә, расларга кирәк булган очракта, территориаль планлаштыру документларын, шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын һәм территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау турында тиешле карарлар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына документлар җибәрү.

4.3. Әлеге Тәртипнең 4.2 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы кабул иткән карарлар җир кишәрлекләрен шәһәр округы милкенә тапшыру турында күрсәтмә актын чыгару максатларында муниципаль районның җирле үзидарә органына җибәрелә.

4.4. Шәһәр округының җирле үзидарә органы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

әлеге Тәртипнең I бүлегендә күрсәтелгән җир кишәрлекләрен милеккә кабул итү чаралары;

күпбалалы гаиләләргә бирү өчен җир кишәрлекләрен булдыру;

күпбалалы гаиләләргә бирү максатларында җир кишәрлекләре исемлеген төзү;

тиешле республика башкарма хакимият органнары белән берлектә, шәһәр округы территориясендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

җир кишәрлеген алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә кертелгән күпбалалы гаиләгә җир кишәрлеге бирү турында карар кабул итү һәм җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актына кул кую;

бирелгән җир кишәрлекләренә хокуклар күчүне рәсмиләштерүне тәэмин итү;

күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирүне мониторинглау.